Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең
Болгар-2 авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
КАРАРЫ

27 ноябрь 2021 ел №6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021елның 27ноябре 11 сәгать 00 минутта, узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлегенең Болгар-2 авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү максатыннан түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:юлларны норматив хәлгә җиткерү, сметалартөзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерүөчен түләү?» сораулары буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 72 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 41 кеше, бу 56,9% тәшкилитә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 24-е«РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

гражданнар җыенында катнашучыларның17-е «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Болгар-2 авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районыИске Михайловка җирлегенең Болгар-2 авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче һәр кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 1000 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: юлларны норматив хәлгә җиткерү, сметалартөзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?».

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, Иске Михайловка авылы, Школьная урамы, 43нче йорт, Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.М.Абдуллин